РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КУКМОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.10.2020 г.Кукмор № 602

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыру белән тәэмин итү турында» 2019 елның 07 ноябрендәге 617 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15, 17 һәм 20 статьялары, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 9 һәм 37 статьялары нигезендә һәм укучыларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты акчалары исәбеннән өстәмә социаль ярдәм чаралары күрсәтү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турында» 2009 елның 7 ноябрендәге 617 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмалары укучыларын тукландыруны оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә (алга таба – Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 1.2 пунктында «Россия Федерациясендә мәгариф турында» сүзләреннән соң «(алга таба – Мәгариф турында Закон)» сүзләрен өстәргә)»;

1.2. Нигезләмәнең 1.3 пунктында:

а) түбәндәге эчтәлекле җиденче һәм сигезенче абзацларны өстәргә:

«- бушлай кайнар ризык – әлеге Нигезләмәнең 2.11 пунктында күрсәтелгән затларны федераль бюджет, Татарстан Республикасы бюджеты, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы бюджеты ассигнованиеләре хисабына һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка финанслау чыганаклары хисабына көнгә кимендә бер тапкыр, кайнар

эчемлекне исәпләмичә, кайнар ризык булуны күздә тота торган кайнар туклану белән тәэмин итү;

- сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) белем алучылар өчен түләүсез туклану – әлеге Нигезләмәнең 2.12 пунктында күрсәтелгән затларны түләүсез туклану белән тәэмин итү;»;

б) җиденче-унбишенче абзацларны унтугызынчы-унҗиденче абзацлар дип санарга;

в) унҗиденче абзацта (яңадан нумерлауны исәпкә алып) текст буенча «ундүртенче» сүзен «уналтынчы» сүзенә алмаштырырга;

1.3. Нигезләмәнең II бүлеге исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«II. Районның гомуми белем бирү оешмаларында туклануны оештыру. Комиссия вәкаләтләре. Ташламалы туклану, бушлай кайнар туклану һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән ( ОВЗ) беле алучылар өчен түләүсез туклану хокукы»;**

1.4. Нигезләмәнең 2.6 пунктындагы беренче абзацында «мондый гаиләләр» сүзләреннән соң, әлеге Нигезләмә нигезендә түләүсез кайнар туклану яки сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) белем алучылар өчен түләүсез туклану хокукына ия укучылар категорияләреннән тыш» сүзләрен өстәргә»;

1.5. Нигезләмәне түбәндәге эчтәлекле 2.11 һәм 2.12 пунктлары белән тулыландырырга:

2.11. Бушлай кайнар туклану Мәгариф турында законның 37 статьясындагы 2.1 өлешендә күрсәтелгән белем алучылар арасыннан укучы балаларга бирелә.

2.12. Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән (ОВЗ) белем алучылар өчен түләүсез туклану, әлеге Нигезләмә нигезендә түләүсез кайнар туклану алу хокукына ия укучылардан тыш, сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар арасыннан укучыларга бирелә.

«Сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучы» төшенчәсе Мәгариф турында законда күрсәтелгән мәгънәдә кулланыла.»;

1.6. Нигезләмәнең 2.11 пунктын 2.13 пункты дип исәпләргә һәм аны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13. Районның гомуми белем бирү оешмасында ташламалы туклану, бушлай кайнар туклану һәм сәламәтлек мөмкинлекләре чикләнгән белем алучылар өчен бушлай туклану уку көннәрендә бирелә.

Өйдә белем алучы укучылар өчен, исәп-хисап аендагы уку көннәре саныннан чыгып, азык-төлек җыелмасы бирелә. Исәп-хисап аена азык-төлек җыелмасын бирү исәп-хисап аеннан соң килүче өченче айның 20 нче числосыннан да соңга калмыйча башкарыла.».

2. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына, әлеге Карарның 1 пункты нигезендә аңа кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып, Нигезләмәне гамәлгә ашыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

**Башкарма комитет җитәкчесе А.Х. Гарифуллин**